| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**07.06.2019** Казан шәһ. № **1167**

Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибен раслау турында

2012 елның 22 декабреннән №87-ЗРТ «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын гамәлгә ашыру максатларында б о е р а м:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары А.Р.Абашевка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

2019 елның 7 июненнән № 1167
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибе

1. Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибе спортчыларны – Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары әгъзаларын (алга таба – спортчылар) медицина-биология ягыннан тәэмин итүнең кагыйдәләрен билгели.

2. Спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү – спортчыларның эшкә сәләтлелеген һәм сәламәтлеген торгызуга юнәлдерелгән (медицина тыкшынуын, психологик характердагы чараларны, спортчыларның сәламәтлеге торышын системалы контрольдә тотуны, спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүне, спорт медицинасы өлкәсендә фәнни тикшеренүләр уздыруны үз эченә алган), физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләп чыгару, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу, шулай ук физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү (спортта допингны булдырмау һәм аңа каршы көрәшне дә кертеп) һәм дәүләт милке белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан расланган бөтенроссия допингка каршы кагыйдәләрнең һәм халыкара допингка каршы оешмалар тарафыннан расланган допингка каршы кагыйдәләрнең законда билгеләнгән физик культура һәм спорт турында таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырыла торган чаралар комплексы.

3. Спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү тиешле эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне), шул санда: «дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы», «медицина реабилитациясе», «клиник фармакология», «функциональ диагностика», «лаборатория эше», «сәламәтлек саклауны оештыру һәм иҗтимагый сәламәтлек» исәпкә ала торган медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләре булган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Кирәкле эш төрләренә (хезмәт күрсәтүләргә) лицензия булмаган очракта, спортчыларны медик-биологик тикшерүне гамәлгә ашыручы оешма таләп ителә торган эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өлешендә медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булган башка оешмалар белән килешү төзи.

Спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы оешмалары исемлеге ел саен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан төзелә (алга таба – Исемлек).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы оешмалары исемлеген килештерә һәм спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыруны контрольдә тота.

4. Спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү мобиль медицина бригадалары тарафыннан гамәлгә ашырыла ала, шул исәптән спорт чараларын хәзерләгәндә һәм үткәргәндә.

5. Спортчыларның эшкә сәләтлелеген һәм сәламәтлеген торгызу, медицина тыкшынуларын үз өченә алып, түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү кысаларында гамәлгә ашырыла:

беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү;

махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтү.

6. Медицина тыкшынуларын үз өченә алып, спортчыларның эшкә сәләтлелеген һәм сәламәтлеген торгызу медицина ярдәмен күрсәтүнең аерым профильләре, авырулар яисә торышлар (авырулар төркемнәре) буенча тәртипләренә туры китереп гамәлгә ашырыла.

7. Беренчел медик-санитар ярдәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм медицина реабилитациясе буенча чараларны, физик йөкләнешләрнең спортчылар сәламәтлеге торышына адекватлыгын бәяләүне, аларның сәламәтлеген торгызуны үз өченә ала.

8. Беренчел медик-санитар ярдәм спортчыларга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә башкарыла торган тиешле эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләре булган оешмаларның медицина хезмәткәрләре тарафыннан һәм әлеге Тәртипкә №1 кушымтада каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып күрсәтелә.

9. Махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме спортчыларга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәткәндә башкарыла торган тиешле эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләре булган оешмаларның медицина хезмәткәрләре тарафыннан һәм әлеге Тәртипкә №2 кушымтада каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып күрсәтелә.

10. Ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме спортчыларга 2013 елның 20 июненнән №388н «Ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы белән расланган Ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтү тәртибенә туры китереп күрсәтелә.

11. Спортчыларның сәламәтлеге торышын систематик контрольдә тоту беренчел һәм периодик медицина тикшерүләрен, шул исәптән тирәнтен медицина тикшерүләрен (алга таба – ТМТ), функциональ торышны күзәтүне һәм коррекцияләүне, этаплы һәм агымдагы медицина тикшеренүләрен, табиб-педагоглар тарафыннан күзәтүләрне үткәрүне үз өченә ала һәм 2016 елның 1 мартыннан №134н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы белән расланган Спорт хәзерлеге узарга, оешмаларда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яки) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулары (тестлары) нормативларын үтәргә теләгән затларны медицина тикшерүе тәртибен кертеп, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән

физкультура чараларын һәм спорт чараларын хәзерләгәндә һәм уздырганда) медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибенә туры китереп, әлеге Тәртипкә №3 кушымтада каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

12. Психологик характердагы чаралар үз эченә ала:

спортчының психологик торышын һәм һөнәри мөһим психофизиологик характеристикаларын диагностик контрольдә тоту, коррекцияләү;

спорт эшчәнлегенең уңышлы булуын билгели торган спортчының һөнәри мөһим характеристикаларын һәм индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен диагностикалау, үстерү һәм саклау;

спортчының психологик торышының начар үзгәрешләрен, донозологик психосоматик һәм дезадаптацион бозылуларны диагностикалау, профилактикалау һәм коррекцияләү;

травмалардан һәм авырулардан соң психологик реабилитация.

13. Спортчыларга психологик характердагы чаралар Россия Федерациясе законнарына туры китереп гамәлгә ашырыла.

14. Спортчыга медицина ярдәме күрсәтү медицина тыкшынуына мәгълүмати ирекле ризалык, шулай ук аның сәламәтлеге торышы турында мәгълүматны тапшырырга рөхсәт ителгән затларны күрсәтү белән аның сәламәтлеге торышы турында мәгълүматны бирүгә ризалык нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Бөтендөнья допингка каршы агентлыкның Тыелган исемлегенә керә торган субстанцияләрне һәм (яки) алымнарны куллану 2018 елның 30 маеннан №288н «Россия Федерациясе спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы белән расланган Россия Федерациясе спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру Тәртибенең 15 пунктына туры китереп гамәлгә ашырыла.

16. Спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре һәм махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү үз эченә ала:

спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларының медицина персоналына медицина, фәнни һәм башка җиһазлар, чыгым материаллары һәм инструментария бирү.

Спорт чараларын үткәрү вакытында спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү буенча функцияләрне гамәлгә ашыру өчен дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары резервы булдырыла.

Спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү тәртибе әлеге Тәртипкә №4 кушымта белән каралган.

17. Спорт медицинасы өлкәсендә фәнни тикшеренүләр спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген төп юнәлешләр буенча арттыру максатларында оештырыла:

югары казанышлар спортын медицина-биология ягыннан тәэмин итү;

югары казанышлар спортын психофизиологик һәм медик-психологик яктан тәэмин итү;

балигъ булмаган спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү;

спорт медицинасында мәгълүмати технологияләр;

спортив туклану;

фармакология белән тәэмин итү.

18. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, шулай ук физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче башка оешмаларның карамагында булган тренировка базаларында (алга таба – тренировка базалары) спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү буенча чаралар тиешле эш төрләренә (хезмәт күрсәтүләргә) лицензиясе булган оешмалар һәм тренировка базалары арасында законнар белән билгеләнгән тәртиптә төзелгән килешүләр нигезендә үткәреләләр.

19. Спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы медицина оешмалары хезмәткәрләре арасыннан һәм Татарстан Республикасы спорт федерацияләре тәкъдимнәрен исәпкә алу белән югары һәм урта һөнәри белемле белгечләр җәлеп ителә.

20. Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларының медицина хезмәткәрләре:

спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итәләр;

спортчының медицина күрсәтүләре булганда спортчыга Бөтендөнья допингка каршы агентлыгы раслаган Халыкара терапевтик куллану буенча стандарт нигезләмәләре нигезендә тыелган субстанция һәм (яки) тыелган алымны терапевтик куллану буенча запросны (алга таба - запрос) рәсмиләштерүдә ярдәм итәләр;

үзләренә беркетелгән медицина, фәнни һәм башка җиһазларның нәтиҗәле, куркынычсыз эксплуатацияләүнен һәм саклануын оештыралар;

бирелә торган дару препаратларының, медицина эшләнмәләренең, биологик актив өстәмәләрнең һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктларының спортчылар тарафыннан кулланылуын контрольдә тоталар;

спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр һәм клиник тикшеренүләр үткәрүдә катнашалар;

комплекслы фәнни төркемнәр хезмәткәрләре һәм спорт төрләре буенча җыелма командаларны фәнни-методик тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар белән хезмәттәшлек итәләр;

Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының баш (өлкән) тренерына спортчыларны медицина-биология ягыннан тәэмин итү чаралары турында хәбәр итәләр;

Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының баш (өлкән) тренерына спортчының тренировка чараларына һәм спорт ярышларында катнашуга кертү өчен каршы күрсәтүләрнең булуы турында хәбәр итәләр һәм спортчыга ачыкланган каршылыкларны бетерүгә юнәлдерелгән кирәкле медицина ярдәме күрсәтүне оештыралар (координациялиләр);

спортта допинг куллануга каршы тәэсир итү буенча укыту программаларында елга 1 тапкырдан да ким булмаган санда катнашалар.

21. Спортчыны Татарстан Республикасы җыелма командасы составына керткәндә элек аны медицина ягыннан тәэмин иткән медицина оешмасы спортчыга яки аның законлы вәкиленә, шулай ук (спортчы яки аның законлы вәкиле ризалыгы булган очракта) – кызыксынган затларга, аңа күрсәтелгән медицина ярдәме һәм үткәрелгән тирәнәйтелгән медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре турында төп мәгълүматларны тәшкил итүче медицина документларының күчермәләрен спортчының яисә аның законлы вәкиленең запросы медицина оешмасы тарафыннан алынган көннән соң 10 эш көне эчендә бирергә тиеш.

22. Спортчыны Татарстан Республикасы җыелма командасы исәбеннән төшереп калдырганда аны медицина ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы медицина оешмасы спортчыга яисә аның законлы вәкиленә, шулай ук (спортчы яки аның законлы вәкиле ризалыгы булган очракта) – кызыксынган затларга, аңа күрсәтелгән медицина ярдәме һәм үткәрелгән тирәнәйтелгән медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре турында төп мәгълүматларны тәшкил итүче медицина документларының күчермәләрен спортчының яисә аның законлы вәкиленең запросы медицина оешмасы тарафыннан алынган көннән соң 10 эш көне эчендә бирергә тиеш.

23. Медицина оешмасына запрос мөрәҗәгать итүче тарафыннан язма формада шәхсән җибәрелә яки почта аша яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

24. Күрсәтелгән медицина ярдәме, шулай ук үткәрелгән тирәнәйтелгән медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре турында төп мәгълүматларны тәшкил итүче медицина документларының күчермәләре мөрәҗәгать итүчегә шәхсән бирелә яки почта аша яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Татарстан Республикасы спорт
җыелма командалары спортчыларын
медицина-биология ягыннан тәэмин
итүне оештыру тәртибенә №1 кушымта

Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларына беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларына (алга таба-спортчылар) Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы медицина оешмаларында (алга таба – Татарстан Республикасы медицина оешмалары) беренчел медик-санитар ярдәмне оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. Татарстан Республикасы медицина оешмаларында спортчыга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне оештыру гамәлгә ашырыла:

планлы формада беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү кирәк булган очракта – табиб-терапевт, участок табиб-терапевты, гомуми практика табибы (гаилә табибы), спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы табибы тарафыннан, Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы спортчысы статусын раслаучы документлар булганда;

кичектергесез формада беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү кирәк булган очракта – табиб-терапевт, участок табиб-терапевты, гомуми практика табибы (гаилә табибы), ашыгыч медицина ярдәме бригадасы табибы яки фельдшеры, спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы табибы тарафыннан.

3. Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү спортчының сәламәтлеге торышын, авыруның (торышының) стадиясе, чагылышы дәрәҗәсен һәм аерым үзенчәлекләрен бәяләү нигезендә башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы раслаган медицина ярдәме төрләре буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәгә, медицина ярдәме күрсәтү тәртипләренә туры китереп һәм медицина ярдәме стандартларын, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын исәпкә алып, спортчыга кирәкле күләмдә Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Спортчыларга беренчел медик-санитар ярдәм бөтенроссия допингка каршы кагыйдәләр һәм халыкара допингка каршы оешмалар тарафыннан расланган допингка каршы кагыйдәләр таләпләре нигезендә күрсәтелә.

5. Спортчыларга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә спортта тыелмаган субстанцияләрне һәм (яки) алымнарны куллануны күздә тотучы дәвалау һәм диагностика алымнарына өстенлек бирелә.

6. Спортчыларга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә Бөтендөнья допингка каршы агентлыкның Тыелган исемлегенә керә торган субстанцияләрне һәм (яки) алымнарны куллану кирәк булган очракта, медицина оешмасы табибы бу хакта спортчыга, шулай ук спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан

Республикасы спорт җыелма командасының табибына (җаваплы вәкиленә) хәбәр итә.

7. Спортчының Татарстан Республикасы медицина оешмасында булу вакытында спорт медицинасы буенча табиб, башка белгечлекләр табиблары спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы белән, спортчының ризалыгы белән – команданың җаваплы вәкиле белән спортчының сәламәтлеге торышы, тикшерү һәм дәвалау планы, реабилитация-торгызу чаралары үткәрү буенча рекомендацияләр, тренировкалар процессын корректировкалау турында мәгълүматны оператив бирү мәсьәләләре буенча актив хезмәттәшлек итәләр.

8. Спортчыга махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина күрсәтүләре булган очракта, медицина ярдәменең әлеге төрен күрсәтү әлеге Тәртипнең №2 кушымтасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

9. Спортчыны карап тикшерү нигезендә бәяләмә рәсмиләштерелә һәм спортчыга бирелә, анда күрсәтелә:

билгеләнгән диагноз;

үткәрелгән тикшерү һәм дәвалау турында җентекле мәгълүматлар (әгәр уздырылган булса);

реабилитация-торгызу чараларының индивидуаль программасы (әгәр кирәк булса);

спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы, спорт медицинасы буенча табиб яки ачыкланган авыруның (авыруга шикләнү) профиле буенча табиб-белгеч тарафыннан алга таба күзәтү планы, шулай ук дәвалау планы;

алдагы карап тикшерүләр графигы;

тренировкалар процессын корректировкалау буенча рекомендацияләр (кирәк булса, спорт медицинасы буенча табиб тарафыннан бирелә);

дару препаратларын һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрне терапевтик куллануга рөхсәтне рәсмиләштерү турында мәгълүматлар (рәсмиләштерү очрагында).

Бәяләмә спорт медицинасы буенча табиб (яисә табиб-белгеч) тарафыннан имзалана һәм беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмасының мөһере белән таныклана.

Татарстан Республикасы спорт
җыелма командалары спортчыларын
медицина-биология ягыннан тәэмин
итүне оештыру тәртибенә №2 кушымта

Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары спортчыларына махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларына (алга таба – спортчылар) Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы медицина оешмаларында (алга таба - Татарстан Республикасы медицина оешмалары) махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәмен оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. Медицина оешмасы спортчыга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәмен медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гамәлдәге лицензия кысаларында кирәкле күләмдә күрсәтә.

3. Спортчыга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтү планлы тәртиптә тиешле профильле медицина оешмасында авыру профиле буенча табиб-белгечнең, спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы табибының юлламасы буенча, яисә башка медицина оешмасыннан күчерү, шулай ук спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы белән килешү буенча үзе мөрәҗәгать итү тәртибендә Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы спортчысы статусын раслаучы документлар булганда гамәлгә ашырыла.

Ашыгыч һәм кичектергесез формаларда медицина ярдәме күрсәтү авыруның профиле буенча башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан расланган медицина ярдәме төрләре буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәгә, медицина ярдәме күрсәтү тәртипләренә туры китереп һәм медицина ярдәме стандартларын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы медицина оешмасына кергәннән соң, спортчыга спорт медицинасы буенча табиб консультациясе оештырылырга тиеш, алга таба спорт медицинасы буенча табиб дәвалау процессында катнаша (дәвалаучы табиб белән бергә тикшерү планын, дәвалау схемасын килештерә, спортчының билгеләнүләрне үтәвен контрольдә тота), тиешле медицина документларын рәсмиләштерү белән.

Спортчы башка медицина оешмасына (Татарстан Республикасыннан читтә) кергәндә, спорт медицинасы буенча табиб консультациясе Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле медицина оешмасы тарафыннан оештырыла.

5. Спортчы медицина оешмасында булганда дәвалаучы табиб спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы белән, спортчының язма ризалыгы буенча күрсәтелгән башка затлар белән спортчының сәламәтлеге торышы, тикшерү һәм дәвалау планы, реабилитация-торгызу чаралары үткәрү буенча рекомендацияләр бирү, тренировкалар процессын корректировкалау турында мәгълүматны оператив бирү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә.

6. Махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме спортчының сәламәтлеген, авыруның (торышының) стадиясен, чагылышы дәрәҗәсен һәм аерым үзенчәлекләрен бәяләү нигезендә авыруның профиле буенча башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы раслаган медицина ярдәме төрләре буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәгә, медицина ярдәме күрсәтү тәртипләренә туры китереп һәм медицина ярдәме стандартларын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын исәпкә алып, спортчыга кирәкле күләмдә медицина оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Спортчыларга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтү Бөтенроссия допингка каршы кагыйдәләре һәм халыкара допингка каршы оешмалар тарафыннан расланган допингка каршы кагыйдәләр таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Спортчыларга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәткәндә спортта тыелмаган субстанцияләрне һәм (яки) алымнарны куллануны күз алдында тота торган дәвалау һәм диагностика алымнары кулланыла.

9. Спортчыларга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәткәндә Бөтендөнья допингка каршы агентлыкның Тыелган исемлегенә керә торган субстанцияләрдән һәм (яки) алымнардан файдалану кирәклеге очрагында, медицина оешмасы табибы бу хакта спортчыга, шулай ук спорт төре буенча Татарстан Республикасы җыелма командасының табибына(җаваплы вәкиленә) хәбәр итә.

10. Махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтүнең тиешле күләмен күрсәтә алмаганда, спортчы башка медицина оешмасына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектында урнашкан, авыруның профиле буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

11. Спортчыны чыгарыр алдыннан медицина оешмасының спорт медицинасы буенча табибы (яки спорт медицинасы буенча табиб-консультант) спортчыны карап тикшерергә, билгеләнгән дәвалау буенча аңлатмалар бирергә, реабилитация-торгызу чараларының индивидуаль программасын төзергә, тренировкалар процессын корректировкалау буенча рекомендацияләр бирергә тиеш.

12. Учреждениедә махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтү тәмамланганнан соң, спортчыга чыгару эпикризы бирелә, анда күрсәтелә:

билгеләнгән диагноз;

үткәрелгән тикшерү һәм дәвалау турында җентекле мәгълүматлар;

реабилитация-торгызу чараларының индивидуаль программасы (әгәр кирәк булса);

алга таба күзәтү планы (спорт төре буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы, спорт медицинасы буенча табиб яки Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән билгеләнгән медицина оешмасының башка белгечлек табибы тарафыннан) һәм дәвалау планы, алга таба тикшерүләрнең ешлыгын һәм периодиклыгын күрсәтү белән (карап тикшерүнең тәкъдим ителгән срокларын күрсәтү белән);

тренировкалар процессын корректировкалау буенча рекомендацияләр;

дару препаратларын һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрне терапевтик куллануга рөхсәтне рәсмиләштерү турында мәгълүмат (әгәр уздырылган булса).

Татарстан Республикасы спорт
җыелма командалары спортчыларын
медицина-биология ягыннан тәэмин
итүне оештыру тәртибенә №3 кушымта

Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары
спортчыларын тирәнтен медицина тикшерүләре
оештыру буенча нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасының медицина оешмаларында Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын (алга таба - спортчылар) тирәнтен медицина тикшерүләре (алга таба – ТМТ) оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. ТМТ кысаларында өстәмә диагностик тикшеренүләр, консультацияләр һәм дәвалау процедураларын оештыруны кертеп, спортчыларга ТМТ үткәрү спортчыларны тирәнтен медицина тикшерүе күләмендә эшләрне башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган медицина оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Спортчыларга ТМТ үткәрү максаты белән медицина оешмасында спортчыларның сәламәтлеге торышы һәм функциональ торышы турында бәяләмә бирә торган комиссия төзелә.

4. Татарстан Республикасы спорт федерацияләре медицина оешмаларына алдагы елның 1 декабренә кадәр срокта федерациянең рәсми бланкында 2016 елның 1 мартыннан №134н «Спорт хәзерлеге узарга, оешмаларда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яки) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулары (тестлары) нормативларын үтәргә теләгән затларны медицина тикшерүе тәртибен кертеп, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын хәзерләгәндә һәм уздырганда) медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгына туры китереп, спорт төрен (спорт дисциплинасын), спортчыларның составын, яшь төркемен, алдан санын һәм ТМТ үткәрү срокларын күрсәтеп, беренчел җыелма гаризалар тапшыралар.

5. Татарстан Республикасы спорт федерацияләренең беренчел җыелма гаризалары нигезендә, спортчыларга ТМТ уздыра торган медицина оешмасы ТМТ срокларын күрсәтү белән ТМТ үткәрүнең еллык графигын төзи.

6. Спортчыларны ТМТ үткәрүгә төгәлләштерелгән җыелма гариза Татарстан Республикасы спорт федерациясе тарафыннан төзелә һәм килештерү өчен ТМТ үткәрүче медицина оешмасына федерациянең рәсми бланкында җибәрелә (ТМТ үткәрүнең уйланылган көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча).

7. Төгәлләштерелгән җыелма заявкада спорт төре (спорт дисциплинасы), спортчыларның составы, яшь төркемнәре, Ф.И.О., аларның туган көннәре,

затларны раслаучы документлар сериясе, номерлары һәм ТМТ үткәрү сроклары күрсәтелгән булырга тиеш.

8. ТМТ үткәрү алдыннан 5 көннән дә соңга калмыйча, ТМТ үткәрә торган медицина оешмасы хәбәрнамә тәртибендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына Татарстан Республикасы спорт федерациясе спортчыларына ТМТ уздырырга ниятләве турында хәбәр итә. Белдерүдә спорт төре (спорт дисциплинасы), спортчыларның составы, яшь төркемнәре, саны һәм ТМТ үткәрү сроклары күрсәтелгән булырга тиеш.

9. Татарстан Республикасының спорт җыелма командасы составына беренче тапкыр кертелгән спортчылар элек күрсәтелгән медицина ярдәме турында мәгълүматлар булган медицина документлары белән ТМТнә килергә тиешләр.

10. Спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасының җыелма командасы табибы ТМТ үткәрү вакытында спортчыларга ТМТ үткәрүче учреждениегә спортчыларны озата барырга, өстәмә диагностик һәм дәвалау чаралары планын төзүдә катнашырга, ТМТ нәтиҗәләре буенча бирелгән рекомендацияләрнең спортчы тарафыннан үтәлешенә ярдәм итәргә тиеш.

11. Тикшерү башланыр алдыннан спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы табибы спортчыларны ТМТ максатлары һәм бурычлары, консультация һәм диагностик тикшеренүләр үткәрүнең этаплылыгы турында хәбәр итә, алга таба спортчының ТМТ үткәрүгә ирекле мәгълүмати ризалыкка имзасын кую белән.

12. 15 яшькә җитмәгән спортчылар, ТМТнә законлы вәкил белән бергә, яисә үзе белән законлы вәкил тарафыннан имзаланган медицина тыкшынуына мәгълүмати ирекле ризалык һәм спортчы сәламәтлеге торышы турында мәгълүматны тапшыру рөхсәт ителгән затларны күрсәтү белән аның сәламәтлеге торышы турында мәгълүмат бирергә ризалык, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белән килергә тиешләр.

13. Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының баш тренеры (ул булмаган очракта вәкаләтле вәкил) спортчыларның ТМТнә килүләрен тәэмин итә.

14. ТМТ нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән оешмаларның комиссияләре тарафыннан спортчының тренировкалар һәм ярышлар эшчәнлегенә кертү статусы билгеләнә:

«Кертелгән» – спортчы төп тренировкалар планы буенча чикләүләрсез тренировкалар һәм ярышлар процессларына кертелгән;

«Кертелмәгән» – кертелмәүнең сәбәбен күрсәтү белән (тулысынча тикшерелеп бетмәү, авыру буенча) спортчы тренировкалар һәм ярышлар эшчәнлегенә кертелмәгән;

«Шартлы рәвештә кертелгән» – спортчы хәзерләнүнең индивидуаль планы буенча тренировкалар һәм ярышлар процессларына кертелгән яки шартлы рәвештә кертелүнең билгеләнгән сроклары нигезендә организм функцияләре параметрларын контрольдә тоту таләп ителә.

15. ТМТ нәтиҗәләре буенча документлар төзелә:

спортчыны тренировкалар һәм ярышлар эшчәнлегенә (кертү яки шартлы рәвештә кертү очрагында) кертү турында медицина бәяләмәсе;

спортчыларның сәламәтлеге һәм функциональ торышы турында җыелма бәяләмә.

16. ТМТ нәтиҗәләре буенча барлык бәяләмәләргә ТМТ үткәрә торган медицина оешмасы комиссиясе рәисе белән имзалана һәм медицина оешмасы мөһере белән таныклана.

17. ТМТ үткәрүче медицина оешмасы, спортчының тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән мәгълүмати ризалыгы булганда, медицина бәяләмәләрен Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының Баш тренерына (ул булмаган очракта вәкаләтле вәкилгә) ТМТ уздыру датасыннан башлап 7 эш көне эчендә тапшыра.

Татарстан Республикасы спорт
җыелма командалары спортчыларын
медицина-биология ягыннан тәэмин
итүне оештыру тәртибенә №4 кушымта

Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын дару чаралары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын (алга таба - спортчылар) дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. Спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырыла.

3. Спортчыларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү спортчыларны авырулардан, имгәнүләрдән һәм физик йөкләнешләрдән соң дәвалауга һәм торгызуга юнәлдерелгән һәм үз эченә ала:

дару препаратларына, медицина эшләнмәләренә, биологик актив өстәмәләргә һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктларына еллык заявканы формалаштыру;

дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары сатып алу;

спортчыларга дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары бирү.

4. Гомуми еллык заявка спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының спорт медицинасы буенча табибы тарафыннан төзелә һәм дару препаратларына, медицина эшләнмәләренә, биологик актив өстәмәләргә һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктларына ихтыяҗны дәлилләүне үз эченә алырга тиеш.

5. Ихтыяҗны дәлилләү нигезләнә:

спортчыларның саны турында мәгълүматларда;

спорт чараларын үткәрү срокларында;

ярышлар һәм тренировкалар эшчәнлегенең үзенчәлекләре турында мәгълүматларда (тренировкалар йөкләнеше интенсивлыгы);

соңгы тирәнәйтелгән медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча спортчыларның сәламәтлеге торышы турында белешмәләрдә;

спорт чараларын уздыру вакытында авырулар санының алдагы елга караганда да ким булмаган күрсәткечләрендә.

6. Заявка Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан килештерелә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана.

7. Спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы җыелма командасының спорт медицинасы буенча табибы (массаж буенча шәфкать туташы) (алга таба-җыелма команданың медицина персоналы):

спорт хәзерлегенә һәм дәвалауга фармакологик ярдәм күрсәтү процессында кулланыла торган дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары турында спортчыга тулы мәгълүмат бирә, шул санда атамасы, бирүнең максаты, куллануга күрсәтүләре һәм каршы күрсәтүләре, яраклылык срогы, партия реквизитлары турында мәгълүматны;

бирү турында мәгълүматны билгеләп кую белән спортчыга кирәкле дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары бирә;

закон таләпләренә туры китереп дару чараларын, медицина эшләнмәләрен, биологик актив өстәмәләрне һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктларын исәптә тотуны һәм саклауны алып бара.

8. Дару препаратын биргәндә аның беренчел упаковкасын бозу тыела.

9. Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибенең 14 пунктында каралган медицина тыкшынуына мәгълүмати ирекле ризалык биреп, спортчы Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының табибы тәкъдим иткән дару препаратлары, медицина өстәмәләре, биологик актив өстәмәләр куллануга ризалык бирә, шулай ук спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары куллануга язма ризалык бирә.

10. Спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының спорт медицинасы буенча табибы хәбәрнамә тәртибендә квартал саен (хисап кварталыннан соң килүче айның 15 көненә кадәр) Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына командада кулланылган дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, биологик актив өстәмәләр һәм спортчыларны тукландыру өчен махсуслаштырылган азык-төлек продуктлары турында хәбәр итә. Хәбәрнамә Татарстан Республикасы спорт федерациясенең рәсми бланкында рәсмиләштерелә һәм спортчыларның шәхси мәгълүматларын тәшкил итәргә тиеш түгел.